ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексы аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2020 елның 11 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Бюджет кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 4 – 5; 2005, № 6 (II өлеш), № 10 (I өлеш), № 12 (IV өлеш); 2006, № 6 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2007, № 8, № 10; 2008, № 8 (III өлеш), № 10 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (I өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 11 (I өлеш), № 11 (II өлеш); 2012, № 11 (I өлеш); 2013, № 7, № 10, № 11 (I өлеш); 2014, № 5, № 12 (III өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 8 – 9; 2016, № 3, № 6 (III өлеш), № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 19 (I өлеш), № 79 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) $31^{1.2}$ статьяның 2 пунктында «һәм үтәлә» сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 37 статьяда:

а) 4 пунктта «һәм үтәлә» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Гарантның принципалга карата регресс таләбе хокукын барлыкка китерми торган Татарстан Республикасы дәүләт гарантиясе (муниципаль гарантия) 100 процент акцияләре (өлешләре) Татарстан Республикасында (муниципаль берәмлектә) (гарантта) булган хуҗалык итү ширкәте, мөлкәте Татарстан Республикасы (муниципаль берәмлек) (гарант) милкендә булган дәүләт (муниципаль) унитар предприятиесе йөкләмәләре буенча гына бирелергә мөмкин.»;

в) 11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Принципалның кредит (заем, шул исәптән облигацияле заем) буенча йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итә торган Татарстан Республикасы дәүләт гарантиясе (муниципаль гарантия) төп йөкләмәнең Татарстан Республикасы дәүләт гарантиясендә (муниципаль гарантиядә) күрсәтелгән, гарантның алдан бирелгән

язмача ризалыгыннан башка үзгәртелә алмый торган шартлары гарантның алдан бирелгән язмача ризалыгыннан башка үзгәртелгән очракта һәм (яисә) Татарстан Республикасы дәүләт гарантиясе (муниципаль гарантия) белән тәэмин ителгән, кредитор тарафыннан аңа карата Россия Федерациясе законнары һәм (яисә) кредит шартнамәсе һәм кредитка Татарстан Республикасы дәүләт гарантиясе (муниципаль гарантия) бирелү шартнамәсе нигезендә кредит акчаларын максатчан файдалануны тикшереп тору гамәлгә ашырыла торган кредит (заем, шул исәптән облигацияле заем) акчаларын максатчан булмаган файдаланган очракта гына гарант тарафыннан чакыртып алынырга тиеш.»;

г) 16 пунктның 5 пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга;

д) 27 пунктта «заемнар» сүзеннән соң «(шул исәптән облигацияле заемнар)» сүзләрен өстәргә;

е) 28 пунктта «заем» сүзеннән соң «, шул исәптән облигацияле заем» сүзләрен өстәргә;

3) $53^2$ статьяның 2 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Кабул ителә торган йөкләмәләрне үтәүгә бюджет ассигнованиеләрен планлаштыру гамәлдәге йөкләмәләрне үтәүгә бюджет ассигнованиеләрен беренче чиратта планлаштырганда гамәлдә булган һәм үтәлмәгән йөкләмәләрне исәпкә алып башкарыла.»;

4) 78 статьяның 3 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Бюджет акчаларын алучы яңа бюджет йөкләмәләрен аңа җиткерелгән бюджет йөкләмәләренең тиешле лимитлары һәм кабул ителгән, ләкин үтәлмәгән бюджет йөкләмәләре арасындагы аермадан артмаган күләмдә кабул итә.».

**2 статья**

Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 17 статьясындагы 2 һәм 3 пунктларының, 18 статьясындагы 2 һәм 3 пунктларының, 29 статьясының 10 пунктындагы 2 пунктчасының, $31^{1.1}$ статьясындагы 3 пунктының, $31^{1.2}$ статьясындагы 3 пунктының, $31^{1.3}$ статьясындагы 3 пунктының, 32 статьясындагы 3 пунктының, $32^1$ статьясындагы 3 пунктының, 43 статьясындагы бишенче абзацының (федераль законнарда билгеләнгән очраклар өлешендә), $44^4$ статьясының 3 пунктындагы өченче, алтынчы һәм җиденче абзацларының һәм 4 пунктындагы беренче абзацының, $44^5$ статьясындагы 3 пунктының, $44^6$ статьясының 10 пунктындагы беренче абзацының, $53^1$ статьясындагы 2 пунктының, 61 статьясындагы 1 пунктының, 77 статьясының 3 пунктындагы унбишенче абзацының, 93 статьясындагы 1 пунктының, $97^3$ статьясындагы 3 пунктының (бюджет үтәлеше турында еллык хисапка бәяләмәләр әзерләү сроклары өлешендә), $97^4$ статьясындагы 1 пунктының (срок өлешендә), $97^6$ статьясындагы 2 һәм 3 пунктларының (сроклар өлешендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 4 – 5; 2005, № 6 (II өлеш), № 10 (I өлеш), № 12 (IV өлеш); 2006, № 6 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2007, № 8, № 10; 2008, № 8 (III өлеш), № 10 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12

(I өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 11 (I өлеш), № 11 (II өлеш); 2012, № 11 (I өлеш); 2013, № 7, № 10, № 11 (I өлеш); 2014, № 5, № 12 (III өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 8 – 9; 2016, № 3, № 6 (III өлеш), № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 19 (I өлеш), № 79 (I өлеш) гамәлдә булуын 2021 елның 1 гыйнварына кадәр туктатып торырга.

**3 статья**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
2. 2020 елда Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетларын үтәү «Россия Федерациясе Бюджет кодексының аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору һәм 2020 елда Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү турында» 2019 елның 12 ноябрендәге 367-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләрен исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2020 ел, 18 июнь
№ 28-ТРЗ